МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

К А Р А Р

05.10.2022 Казан ш. № 3

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2022 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2021 елның 6 сентябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2022 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2021 елның 6 сентябрендәге 3 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 28 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «1014» саннарын «1006» саннарына алмаштырырга.

1 нче кушымтада:

1 пунктның 4, 6, 7 һәм 9 графаларында «11992», «7,7», «41», «247» саннарын «11822», «7,8», «40», «243» саннарына туры китереп алмаштырырга;

29 пунктны көчен югалткан дип танырга;

59 пунктны көчен югалткан дип танырга;

100 пунктның 2 графасында «Кнорр-Бремзе КАМА Коммерцияле транспорт чаралары өчен системалар» сүзләрен «КАМАЗ тормоз системалары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

231 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

2 нче кушымтада:

1 пунктның 4, 5, 6, 7 һәм 9 графаларында «70180», «9385», «13,4», «1069», «767» саннарын «69441», «9363», «13,5», «1055», «763» саннарына туры китереп алмаштырырга;

74 пунктның 2 графасында «Содексо ЕвроАзия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте» сүзләрен «АЙЭФСИЭМ ГРУПП» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

147 пунктны көчен югалткан дип танырга;

156 пунктны көчен югалткан дип танырга.

2. «Бөгелмә шәһәре Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Чүпрәле районы Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Киров районы Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Чаллы шәһәре Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Түбән Кама шәһәре Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Чистай шәһәре Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе директорларына әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта әлеге карар кабул итүгә бәйле рәвештә 2022 елга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен оешмаларның исемнәре, билгеләнгән квоталар һәм (яки) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервка куела торган эш урыннары саны үзгәрә торган эш бирүчеләргә язмача рәвештә хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А.Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова